**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

«13» ноябрь, 2023 ел Иштирәк авылы № 4

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Иштирәк авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Иштирәк авылының Үзәк урамы буенча 50А йорты янгын сүндерү депосы бинасы янында Иштирәк, Узәк урамнарында (авылның бер өлеше - авыл) үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын 2023 елның 25 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка билгеләргә

2. Иштирәк авылы, Үзәк һәм С.Закиров урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын 2023 елның 25 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3.Гражданнар җыенын үткәрү өчен Иштирәк авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билге буенча башкарырга кирәк.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2024 елда Иштирәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә килешәсезме? Иштирәк авыл җирлеге Иштирәк авыл җирлегенең I һәм II группа инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз карт гражданнар һәм студентлар, көндезге формада белем алучы күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләүне киметергә һәм әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә түләргә тиеш:
- зиратны төзекләндерү (зират территориясен койма алу һәм урнаштыру);
- күпфатирлы йортлар территориясен төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК».

5. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Иштирәк авыл җирлеге Башлыгы Г.С. Гарифуллина